ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«29» июнь 2021 ел №445

**«2021 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген үстерү» муниципаль программасын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген үстерү, юл-транспорт һәлакәтләрен һәм аларның нәтиҗәләрен киметү чараларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 28 декабрендәге 1206 номерлы карары нигезендә Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «2021 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген үстерү» муниципаль программасын расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru)бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р. Мөхәрәмов

Арча муниципаль районы башкарма
комитетының 29 июнь 2021 ел,
№ 445 карары белән расланды

# «2021 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген үстерү» муниципаль программасы

## ЭЧТӘЛЕК

ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ 3

I. Проблеманы нигезләү. 11

II. Программаның төп максатлары һәм бурычлары. 23

III. Программа чаралары исемлеге. 24

IV. Программаны ресурслар белән тәэмин итү. 24

V. Программаны тормышка ашыру механизмы. 24

1 нче кушымта.
Программа-максатчан метод булмаган шартларда көтелгән авариялелек күрсәткече 26

2 нче кушымта. 2021 елда Арча муниципаль районы территориясендә юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә үлүчеләр санын киметүнең максатчан юнәлешләре 26

3 нче кушымта. Программа чаралары исемлеге 27

4 нче кушымта. "2013-2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген үстерү" федераль максатчан программаны тормышка ашыру еллары буенча максатчан индикаторлар һәм күрсәткечләр 29

# ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | "2021 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген үстерү" муниципаль программасы |
| Программаны эшләү өчен нигез | 1. «Имин һәм сыйфатлы автомобиль юллары» илкүләм проекты паспорты (Россия Федерациясе Президенты каршындагы стратегик үсеш һәм милли проектлар советы президиумы тарафыннан расланды - 2018 елның 24 декабрендәге 15 номерлы беркетмә)<br>2. "2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш" дәүләт программасының (2020 елның 21 ноябрендәге үзгәрешләр белән) "2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген үстерү" ярдәмче программасын раслау турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары<br>3. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 8 гыйнварындагы 1-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган 2018 - 2024 елларга Россия Федерациясендә юл хәрәкәте иминлеге стратегиясе<br>4. «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2014 елның 06 декабрендәге ПУ-1115 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы<br>5. «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген үстерү, юл-транспорт һәлакәтләрен һәм аларның авыр нәтиҗәләрен киметү чараларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 28 декабрендәге 1206 номерлы карары |
| Программаның координаторы | Арча муниципаль районы Советы |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүчеләр | 1. Арча муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге<br>2. Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге ЮХИДИ бүлекчәсе<br>3.«Арча муниципаль районы башкарма комитетының финанс-бюджет палатасы» МКУ<br>4. «Арча муниципаль районының гражданлык яклау идарәсе» МКУ<br>Арча районында «Юл хәрәкәте иминлеге» ДБУ бүлекчәсе катнашында эшләнде |

| | |
|---|---|
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Программаның максаты-юл-транспорт һәлакәтләреннән үлүчеләр (шул исәптән балалар) һәм юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләр санын киметү, гражданнарның гомерен, сәламәтлеген һәм аларның мөлкәтен саклауны тәэмин итү, район автомобиль юллары буйлап хәрәкәт итүнең куркынычсыз шартларына һәм законлы хокукларына гарантияләрне арттыру.<br>Программаның бурычлары:<br>- кешеләрнең һәлак булу ихтималы аеруча зур булган юл-транспорт һәлакәтләрен булдырмау;<br>- юл-транспорт һәлакәтләрендә имгәнүләрне киметү;<br>- юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтүнең заманча системасын камилләштерү;<br>- юл хәрәкәте иминлеген үстерү буенча эшчәнлек белән идарә итү системасын камилләштерү;<br>- юл хәрәкәтендә катнашучыларның хокукый аңын һәм җаваплылыгын үстерү;<br>- җирле әһәмияттәге юлларда куркыныч урыннарны бетерү;<br>- урамнарда һәм юлларда юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү системасын камилләштерү;<br>- авария-коткару эшләренең нәтиҗәлелеген арттыру. |
| Программаның максатчан күрсәткечләре һәм индикаторлары финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | "Имин һәм сыйфатлы автомобиль юллары" илкүләм проекты "2024 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары һәм стратегик бурычлары турында" Россия Федерациясе Президентының 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указын үтәү йөзеннән Россия Транспорт министрлыгы тарафыннан эшләнде һәм үз эченә дүрт федераль проектны ала: «Юл челтәре», «Юл хуҗалыгын үстерү буенча гомуми чаралар», «Юл хәрәкәте иминлеге» һәм «Россия Оборона министрлыгының автомобиль юллары».<br>Илкүләм проектны гамәлгә ашыру срогы: 2018 елның декабреннән 2024 елга кадәр (кертеп).<br>Максатлар һәм максатчан күрсәткечләр:<br>1. Региональ әһәмияттәге автомобиль юлларының норматив таләпләргә туры килә торган өлешен аларның гомуми озынлыгына карата кимендә 50 %ка (аларның 2017 елның 31 декабрендәге торышы буенча) арттыру.<br>2. Артык йөкләнеш режимында эшләүче федераль һәм региональ әһәмияттәге автомобиль юллары өлешен аларның гомуми озынлыгына карата 2017 ел белән чагыштырганда 10 %ка киметү.<br>3. Юл челтәрендә юл-транспорт һәлакәтләре (авария куркынычы булган урыннары) концентрацияләнү урыннары санын 2017 ел белән чагыштырганда ике мәртәбә киметү.<br>4. Юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә үлүчеләр санын 2017 |

| | |
|---|---|
| | ел белән чагыштырганда 3,5 тапкыр кимету (36-4-58, 4/3,5=1) 100 мең кешегә 4 кешедән артмаган дәрәҗәгә кадәр (51291/2, 2030 елга - үлемнәрне бөтенләй булдырмауга омтылу).<br>5. Яңа һәм иң яхшы технологияләр, материаллар һәм технологик карарлар реестрын булдыру һәм илкүләм проект кысаларында юл эшчәнлеген гамәлгә ашыруга контрактларның өлешен (реестрга кертелгән яңа технологияләр һәм материалларны куллануны күздә тота) 2024 ел ахырына 80% ка кадәр җиткерү.<br>6. Илкүләм проект кысаларында юл эшчәнлеген гамәлгә ашыруга контрактларның өлешен юл эшләренең төрле төрләрен бер контрактка берләштерүне күздә тоткан илкүләм проект кысаларында җиткерү 2024 ел ахырына автомобиль юлларын капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту буенча эшләр башкаруга яңа дәүләт контрактларының гомуми күләмендә 70% ка кадәр тәэмин итү.<br>7. Россия Оборона министрлыгының норматив таләпләргә туры килә торган автомобиль юллары өлешен 2024 ел ахырына 60 %ка кадәр арттыру.<br>Россия Федерациясендә 2018 - 2024 елларга юл хәрәкәте иминлеге стратегиясе<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 8 гыйнварындагы 1-р номерлы күрсәтмәсе белән расланды.<br>Стратегияне гамәлгә ашыруның максатлары, төп юнәлешләре, бурычлары, принциплары һәм күрсәткечләре:<br>1. Стратегиянең максаты-юл хәрәкәте иминлеген үстерү, шулай ук 2030 елга юл-транспорт һәлакәтләрендә үлемнәрне булдырмауга омтылу.<br>2. 2024 елга максатчан ориентир буларак социаль куркыныч күрсәткеч билгеләнә, ул 100 мең кешегә 4 һәлак булучыдан артмый.<br>Стратегияне гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре түбәндәгеләр:<br>1. Юл хәрәкәте нормаларын һәм кагыйдәләрен һичшиксез үтәү максатыннан, юл хәрәкәтендә катнашучыларның үз-үзләрен тотышын үзгәртү.<br>2. Юл-транспорт һәлакәтләреннән һәм юл хәрәкәтендә аеруча зыян күрүчеләрне, барыннан да элек балалар һәм җәяүлеләрне саклауны арттыру.<br>3. Юл хәрәкәтен оештыру эшләрен үстерүне дә кертеп, урам-юл челтәрен юл хәрәкәте иминлеге шартлары буенча камилләштерү.<br>4. Транспорт чараларын һәм аларны йөртүчеләрне юл хәрәкәтендә катнашуга кертүнең оештыру-хокукый механизмнарын камилләштерү.<br>5. Юл хәрәкәте иминлеге белән идарә итү системасын |

| | |
|---|---|
| | камилләштерү.<br>6. Юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтү һәм аларны коткару системасын үстерү.<br>Юл хәрәкәте нормаларын һәм кагыйдәләрен һичшиксез үтәү максаты белән, юл хәрәкәтендә катнашучыларның үз-үзләрен тотышын үзгәртүгә бәйле юнәлешне гамәлгә ашыру буенча төп бурычлар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>1. Урамнарда һәм юлларда хәвефсез тәртип стереотипларын булдыру максатында халык өчен махсус, шул исәптән укыту программалары эшләү һәм гамәлгә ашыру.<br>2. Юл хәрәкәтендә катнашучыларның үз-үзләрен тотышын үзгәртү, юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозучыларга һәм юлда үзләрен агрессив тоту фактларына тискәре мөнәсәбәт формалаштыру, хезмәттәшлек принципларын үстерү, юл хәрәкәтендә катнашучылар арасында үзара ышаныч һәм ярдәм итешү принципларын үстерү максатыннан, массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган мәгълүмати-аңлату эшләре практикасын камилләштерү.<br>3. Юл хәрәкәте өлкәсендә контроль-күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашыручы дәүләт органы вәкилләре буларак, Дәүләт автоинспекциясе хезмәткәрләренең уңай имиджын формалаштыру.<br>4. Сәнәгать өлкәсендә эшчәнлек алып баручы җәмәгать оешмаларын, ассоциацияләрен, субъектларны, Россия бизнес-бергәлеге структураларын юл хәрәкәте иминлеген үстерү буенча профилактик эшкә җәлеп итү.<br>5. Юл хәрәкәте кагыйдәләрен үтәүне автомат контрольдә тоту буенча эшләрне, шул исәптән фотога һәм кинога төшерү, видеога яздыру функцияләре булган автоматик режимда эшләүче махсус техник чараларны урнаштыруны тәртипкә салу өлешендә алга таба киңәйтү.<br>6. Иминлек таләпләрен үтәүне стимуллаштыра торган пассажирлар һәм йөкләр ташуда юл хәрәкәте иминлеген арттыру чаралары комплексын гамәлгә ашыру.<br>7. Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә контроль-күзәтчелек эшчәнлеген камилләштерү.<br>8. Салым салу, лицензияләү, мөлкәти иминиятләштерү һәм тарифлар формалаштыру мәсьәләләрен дә кертеп, юл хәрәкәте иминлеге таләпләрен үтәүгә юнәлдерелгән икътисадый стимуллаштыру механизмнарын үстерү.<br>9. Транспорт чаралары хуҗаларының граждан җаваплылыгын иминиятләштерү мәсьәләләре буенча законнарны һәм хокук куллану практикасын комплекслы камилләштерү.<br>Юл-транспорт һәлакәтләреннән якланганлыкны һәм аларның нәтиҗәләрен арттыруга бәйле юнәлешне гамәлгә ашыру буенча |

| | |
|---|---|
| | төп бурычлар булып түбәндәгеләр тора:<br>1. Юл хәрәкәтендә катнашу вакытында балаларның иминлеген тәэмин итү чаралары комплексын гамәлгә ашыру.<br>2. Көчле транспорт агымнары шартларында, аларны анализлауның, модельләштерү һәм фаразлауның заманча ысулларын куллану юлы белән аларның хәрәкәте куркынычын киметү максатыннан, урам-юл челтәрләрендә җәяүлеләр хәрәкәтен оештыруны камилләштерү.<br>3. Җәяүлеләр хәрәкәтен оптималь оештыру ихтыяҗын исәпкә алган җәяүлеләр кичү юлларын (җир өсте, җир асты, җирдәге) комплекслы төзекләндерү Җәяүлеләр кичү юлларын инновацион методлар һәм технологияләр кулланып, юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары җыелмасы белән җиһазлау.<br>Транспорт чараларын һәм аларны йөртүчеләрне юл хәрәкәтендә катнашуга кертүнең оештыру-хокукый механизмнарын камилләштерү белән бәйле юнәлешне тормышка ашыру буенча төп бурычлар:<br>1. Аз чыгымлы, әмма нәтиҗәле чаралар исәбенә юл хәрәкәте иминлеген арттыру өлешендә юл шартларын һәм юл инфраструктурасын камилләштерү (юл-транспорт һәлакәтләренеңкүп була торган урыннарын бетерү, юл тамгалары кую, юл билгеләре һәм күрсәткечләре урнаштыру, маршрут транспорт чаралары тукталышлары урыннарын урнаштыру һәм җиһазлау).<br>2. Җирдән файдалану өлкәсендәге эшләрне башкарганда юл хәрәкәте иминлеге мәсьәләләрен исәпкә алуга, территорияләрне планлаштыруга һәм төзүгә, урам-юл челтәрләрен үстерүгә бәйле тәкъдимнәр әзерләү.<br>3. Югары технологияле электрон һәм мобиль техника нигезендә юл хәрәкәте белән идарә итүне автоматлаштыру принципларын үстерү, юл хәрәкәте белән идарә итү системаларын интеллектуаль транспорт системаларына кертү.<br>Транспорт чараларын һәм аларны камилләштерүгә бәйле юнәлешне гамәлгә ашыру буенча төп бурычлар түбәндәгеләр:<br>1. Тиешле категориядәге транспорт чаралары белән идарә итү хокукын алу өчен кирәкле транспорт чаралары белән идарә итүнең белем һәм күнекмәләре дәрәҗәсенә карата таләпләрне камилләштерү.<br>2. Машина йөртүчеләрне һөнәри укыту буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда машина йөртүчеләргә кандидатларны сыйфатлы әзерләүне тәэмин итүче һәм автомобиль йөртүчеләргә максималь дәрәҗәдә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда уку процессы рәвешләрен һәм методларын камилләштерү. |

| | |
|---|---|
| | 3. "Тәгәрмәчле транспорт чаралары иминлеге турында" таможня берлегенең техник регламенты таләпләренә туры килүен тәэмин итүнең нәтиҗәле механизмын формалаштыру.<br>Юл хәрәкәте иминлеге белән идарә итү системасын камилләштерү белән бәйле юнәлешне тормышка ашыру буенча төп бурычлар:<br>1. Юл хәрәкәте иминлеген арттыру буенча практик чараларны гамәлгә ашыру, беренче чиратта, федераль, региональ һәм муниципаль программалар нигезендә.<br>2. Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү эшчәнлеге белән идарә органнары компетенциясен оптимальләштерү.<br>3. Башкарма хакимият органнарына һәм җирле үзидарә органнарына максатчан биремнәр билгеләү, юл хәрәкәте иминлеге торышына мониторинг үткәрүне оештыру, шулай ук күрсәткечләр һәм индикаторлар үзгәрүне бәяләү буенча тәкъдимнәр әзерләү.<br>4. Федераль башкарма хакимият органнарының, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының, шулай ук юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү эшчәнлегенең башка субъектларының көчләрен координацияләү.<br>5. Юл хәрәкәтендә реаль процессларны нормаларга һәм кагыйдәләргә туры китерү өчен законнарны ныгыту, кылынган хокук бозуның авырлыгының җәзага ярашлылыгын тәэмин итүне дә кертеп.<br>6. Юл хәрәкәте иминлеген үстерү бурычларын хәл итү өчен кирәкле финанслау күләмнәрен һәм чыганакларын билгеләү буенча тәкъдимнәр эшләү, шулай ук бүлеп бирелә торган финанслау күләмнәреннән нәтиҗәле файдалану механизмын эшләү.<br>7. Федераль, региональ һәм муниципаль дәрәҗәләрдә юл хәрәкәтен оештыру чараларын гамәлгә ашыру өчен хокукый һәм оештыру нигезләрен камилләштерү.<br>8. Юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендә, шул исәптән юл хәрәкәтен оештыру мәсьәләләре буенча белгечләр әзерләү һәм квалификация күтәрү институтларын формалаштыру.<br>9. Юл хәрәкәте иминлеге белән идарә итү өлкәсендә илебез һәм чит ил тәҗрибәсен өйрәнүне һәм таратуны оештыру.<br>Юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә зыян күрүчеләрне коткару һәм ярдәм күрсәтү системасын үстерүгә бәйле юнәлешне гамәлгә ашыру буенча төп бурычлар түбәндәгеләр:<br>1. Юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтү институтын үстерү.<br>2. Юл-транспорт һәлакәте барлыкка килү турында сигнал алганда, юл-транспорт һәлакәте урынына чыкканда һәм һәлакәт |

| | |
|---|---|
| | булган урында гамәлләрне координацияләү турында катнашучы хезмәтләрнең үзара хезмәттәшлеге регламентларын эшләү. Бу максатларда мәгълүмати системаларны, шул исәптән "ЭРА-ГЛОНАСС" дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасын актив куллану.<br>3. Һәлакәт урынына чыкканда оператив хезмәтләрнең автотранспортының каршылыксыз хәрәкәтен тәэмин итү чараларын эшләү. Юл-транспорт һәлакәте урынына килү һәм зыян күрүчеләрне дәвалау учреждениеләренә илтү өчен авиация техникасын куллану тәҗрибәсен киңәйтү.<br>Стратегияне гамәлгә ашыру түбәндәге принципларга нигезләнә:<br>1. Хуҗалык эшчәнлегенең икътисадый нәтиҗәләренә карата юл хәрәкәтендә катнашучы гражданнарның тормыш һәм сәламәтлек өстенлеге.<br>2. Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүдә гражданнар, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләрен үтәү.<br>3. Кабул ителә торган карарларның Россия Федерациясе законнары Нигезләмәләренә һәм халыкара йөкләмәләренә туры килүе.<br>4. Җәмгыять өчен үткәрелә торган эшнең ачыклыгы.<br>5. Юл-транспорт имгәнүләрен киметү буенча аз чыгымлы, әмма нәтиҗәле чаралар туплау.<br>6. Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү эшчәнлегендә заманча технологияләрне (интеллектуаль транспорт системалары, глобаль навигация системалары, идарә итү процессын автоматлаштыру системалары, шулай ук транспорт чараларының актив һәм пассив куркынычсызлыгы, юл-транспорт һәлакәтләренең авыр нәтиҗәләрен кисәтүгә һәм киметүгә сыйфатлы йогынты ясый торган башка перспектив системалар) куллану өстенлеге.<br>7. Юл хәрәкәте иминлегенең иң проблемалы зоналарына даими мониторинг нәтиҗәләре нигезендә, шулай ук халыкара экспертлар бергәлеге тарафыннан куркыныч факторларын исәпкә алып, чараларны планлаштыру һәм актуальләштерү (хәрәкәт тизлеген билгеләнгән чикләүне арттыру, исерек хәлдә транспорт чарасы белән идарә итү, куркынычсызлык каешларын, балалар өчен тотып калучы системаларны (җайланмаларны), саклау шлемнарын кулланмау).<br>8. Юл хәрәкәтендә зыян күрүчеләрнең (балалар, җәяүлеләр, инвалидлар), пассажирлар һәм йөк ташуның иминлеген тәэмин итү өстенлеге.<br>Юл хәрәкәте иминлеге торышы күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>1. Юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә китергән зыянны характерлаучы |

| | |
|---|---|
| | күрсәткечләр.<br>2. Җәяүлеләр, балалар, велосипедчылар, мопед йөртүчеләр һәм мотоцикллар катнашында юл-транспорт һәлакәтләрен характерлаучы күрсәткечләр.<br>3. Урам-юл челтәре җитешсезлекләре теркәлгән юл-транспорт һәлакәтләрен характерлаучы күрсәткечләр.<br>4. Транспорт чарасы белән идарә итү стажы 2 елга кадәрге йөртүчеләр гаебе белән булган юл-транспорт һәлакәтләрен характерлаучы күрсәткечләр.<br>5. Транспорт чараларының техник төзексезлеге теркәлгән юл-транспорт һәлакәтләрен характерлаучы күрсәткечләр.<br>6. Юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль идарәнең нәтиҗәлелеген характерлаучы күрсәткечләр.<br>7. Юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә медицина ярдәме күрсәтүнең үз вакытында башкарылуын характерлаучы күрсәткечләр.<br>"Имин һәм сыйфатлы автомобиль юллары" илкүләм проектының максатчан күрсәткечләре Программага 4 нче кушымтада чагылдырылды. |
| Программаны тормышка ашыру сроклары | Программа 2021 елда гамәлгә ашыру өчен каралган |
| Программаны финанслауның чыганаклары һәм күләмнәре | Арча муниципаль районы бюджеты<br>3 007 858,74 сум |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре аның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә үлүчеләр санын 2017 ел белән чагыштырганда 3,5 тапкыр кимету (36-4-58, 4/3,5=1) - 100 мең кешегә  4 кешедән артмаган дәрәҗәгә кадәр (51291/2, 2030 елга - үлемнәр булдырмауга омтылу). |

## I. ПРОБЛЕМАНЫ НИГЕЗЛӘҮ

Юл хәрәкәтендә катнашучыларның тормышын һәм сәламәтлеген саклауны тәэмин итү проблемасы районның социаль-икътисади үсешендәге өстенлекле юнәлешләр арасына керә.

Төбәк һәм җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары муниципаль район инфраструктурасының мөһим элементы булып тора, аларның озынлыгы:

| Исеме | Озынлыгы, км | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | Асфальт | Вак таш | Грунт |
| "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге юл-урам челтәре | 151,625 | 66,166 | 48,931 | 36,528 |
| Җирлекләрнең урам-юл челтәре | 340,704 | 31,735 | 174,146 | 134,823 |
| Муниципаль автомобиль юллары, шәһәрнең урам-юл челтәрен исәпкә алмыйча | 1,890 | 0,700 | 0,200 | 0,990 |
| Муниципаль автомобиль юллары, авыл җирлекләре урам-юл челтәрен исәпкә алмыйча | 236,485 | 6,544 | 18,970 | 210,971 |
| **2020 елның декабренә җирле әһәмияттәге юлларның озынлыгы** | 730,704 | 105,145 | 242,247 | 383,312 |
| **2021 елның 1 гыйнварына төбәк әһәмиятендәге юлларның озынлыгы** | 438,538 | 386,948 | 23,243 | 28,347 |
| Районда автомобиль юллары **барлыгы** | 1169,242 | 492,093 | 265,49 | 411,659 |
| Районда торак пунктлар саны | 128 | | | |
| Каты өслекле керү юллары булмаган торак пунктлар саны | 7+20= 27 (Грунт) | | | |

**Теркәлгән транспорт чаралары саны**

| Еллар | Теркәлгән | Физик затлар | Юридик затлар | Шул исәптән дәүләт һәм муниципаль милек |
|---|---|---|---|---|
| 2009 ел | 4048 | 3694 | 354 | 162 |
| 2010 ел | 4999 | 4652 | 347 | 74 |
| 2011 ел | 6126 | 5762 | 364 | 98 |
| 2012 ел | 5392 | 5084 | 308 | 36 |
| 2013 ел | 5955 | 5595 | 360 | 50 |
| 2014 ел. | 6066 | 5693 | 373 | 78 |
| 2015 ел | 3866 | 3611 | 255 | 52 |
| 2016 ел. | 4986 | 4790 | 196 | 52 |
| 2017 ел. | 4605 | 4342 | 263 | 98 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2018 | 2138 | 1966 | 172 | 73 |
| 2019 | 2121 | 1946 | 175 | 52 |
| 2020 | 9055 | - | - | - |

**Машина йөртү таныклыгы бирелгән**

| Еллар | Барлыгы | Шул исәптән, алмаштырылган |
|---|---|---|
| 2009 ел | 14894 | 10746 |
| 2010 ел | 9290 | 5676 |
| 2011 ел | 9125 | 4988 |
| 2012 ел | 7450 | 3014 |
| 2013 ел | 7852 | 3566 |
| 2014 ел | 8061 | 3861 |
| 2015 ел | 7033 | 3455 |
| 2016 ел. | 6754 | 3778 |
| 2017 ел. | 6280 | 4377 |
| 2018 ел | 8585 | 6830 |
| 2019 ел | 11033 | 8651 |
| 2020ел | 7761 | - |

**Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлегенең ЮХИДИ бүлекчәсе**

| | |
|---|---|
| Хезмәткәрләр штаты, шул исәптән: | 12 |
| Бүлек башлыгы | 1 |
| РЭО башлыгы | 1 |
| РЭО өлкән дәүләт инспекторы | 1 |
| РЭО дәүләт инспекторы | 4 |
| ЮХИДИ бүлеге өлкән дәүләт инспекторы | 1 |
| Юл-патруль хезмәте өлкән инспекторы | 1 |
| юл-патруль хезмәте инспекторы | 2 |
| Махсус транспорт, шул исәптән: | 5 |
| ЛАДА 217050 2013 ел чыг. | 1 |
| ЛАДА 217050 2013 ел чыг. | 1 |
| LADA XRAY 2019 ел чыг. | 1 |

| | |
|---|---|
| Уку автомобиле ЛАДА 217030 2013 ел чыг. | 1 |
| Газ – 2110 уку автомобиле 2008 ел чыг. | 1 |
| Техник чаралар һәм приборлар, шул исәптән: | 6 |
| "Кордон-Темп" фоторадар күчмә комплексы | 3 |
| Тоткарланган транспорт чараларын саклау һәм транспортировка: | 1 |
| «Юл хәрәкәте иминлеге" АКБО махсуслаштырылган автостоянкасы 40 машинага | 1 |
| "Юл хәрәкәте иминлеге" ISUZU маркалы АКБО эвакуаторы | 1 |
| Транспорт чараларын техник карау: | |
| "Таттехконтроль" ААҖ | 1 |

**Авариялелек торышы**

| **Еллар** | **Барлыгы ЮТҺ** | **Матди зыян белән** | **А-Б-В зыян күрүчеләр белән** |
|---|---|---|---|
| 2003 | 249 | 201 | 48-16-58 |
| 2004 | 304 | 256 | 48-10-57 |
| 2005 | 332 | 280 | 52-11-61 |
| 2006 | 390 | 326 | 64-11-92 |
| 2007 | 472 | 420 | 52-8-74 |
| 2008 | 664 | 616 | 48-7-61 |
| 2009 | 807 | 743 | 64-17-74 |
| 2010 | 950 | 878 | 72-14-97 |
| 2011 | 1087 | 1028 | 60-12-81 |
| 2012 | 972 | 914 | 58-9-88 |
| 2013 | 1219 | 1148 | 71-21-96 |
| 2014 | 1303 | 1255 | 50-5-64 |
| 2015 | 1488 | 1445 | 43-4-60 |
| 2016 | 973 | 928 | 45-8-65 |
| 2017 | 707 | 669 | 36-4-58 |
| 2018 | 682 | 651 | 31-6-36 |
| 2019 | - | - | 30-8-38 |
| 2020 | - | - | 28-11-39 |

А(саны) – Б (үлүчеләр)- В(имгәнүчеләр)

«2013-2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген үстерү» федераль максатчан программасы күрсәткечләрен һәм фаразланган максатчан индикаторларны үтәү: 9 һәлак булучы фаразлаган-үтәлмәгән.

2020 елның 12 ае нәтиҗәләре буенча юл-транспорт һәлакәте нәтиҗәсендә үлүчеләр санын киметүнең "БКАД" илкүләм проекты нигезендә исәп-хисап максатчан күрсәткече 8 булса, юл-транспорт һәлакәтендә 11 кеше һәлак булган.

## Балалар катнашында булган аварияләр торышы

| Еллар | Барлыгы балалар белән ЮТҺ | Имгәнүче балалар белән .<br>А-Б-В |
|---|---|---|
| 2006 | 2 | 2-0-1 |
| 2007 | 3 | 3-0-3 |
| 2008 | 6 | 6-0-6 |
| 2009 | 4 | 4-0-4 |
| 2010 | 5 | 5-2-3 |
| 2011 | 7 | 7-1-5 |
| 2012 | 4 | 4-1-4 |
| 2013 | 6 | 6-2-6 |
| 2014 | 7 | 7-0-9 |
| 2015 | 4 | 4-0-4 |
| 2016 | 3 | 3-1-4 |
| 2017 | 6 | 6-0-6 |
| 2018 | 1 | 1-0-1 |
| 2019 | 5 | 5-0-6 |
| 2020 | 4 | 4-0-5 |

А(саны) – Б (үлүчеләр)- В(имгәнүчеләр)

"2020 елда юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булган балалар саны" күрсәткече үтәлгән, фаразлаган  һәлак булган 1 бала- һәлак булучылар юк.

## Һәлакәт төрләре

| Еллар буенча һәлакәтләр төрләре | Барлыгы | | | | | Имгәнгән балалар белән | | | | | Матди зыян белән | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2012 | 2014 | 2015 | 2016 | 2017 | 2012 | 2014 | 2015 | 2016 | 2017 | 2012 | 2014 | 2015 | 2016 | 2017 |
| Бәрелешләр | 384 | 425 | 457 | 483 | 371 | 28-4-49 | 19-4-20 | 13-1-26 | 11-1-21 | 15-1-30 | 356 | 386 | 444 | 472 | 307 |
| Авулар | 61 | 120 | 117 | 216 | 21 | 16-5-25 | 17-0-30 | 14-2-18 | 19-4-25 | 13-0-16 | 45 | 75 | 103 | 197 | 21 |
| Техник чараларны бәрдерү | 320 | 433 | 587 | 421 | 219 | 0 | 0 | 0 | 1-0-1 | 0 | 320 | 418 | 578 | 420 | 132 |
| Киртәләргә бәрелү | 152 | 139 | 154 | 180 | 30 | 4-0-4 | 3-0-2 | 4-0-5 | 3-0-5 | 4-0-8 | 148 | 122 | 150 | 177 | 39 |
| Җәяүлене бәрдерү, | 8 | 5 | 11 | 4 | 7 | 7-0-7 | 8-1-6 | 11-1-10 | 1-2 | 7-3-4 | - | - | - | - | 4 |
| шул исәптән балаларны | 2 | 1 | 1 | 0 | 0 | 3-0-3 | 1-0-1 | 1-0-1 | 0 | 1-0-1 | - | - | - | - | 0 |
| Велосипедны бәрдерү, | 0 | 1 | 0 | 0 | 0 | - | 1-0-1 | 0 | 0 | 0 | - | - | - | - | - |
| шул исәптән балаларны | 0 | 1 | 0 | 0 | 0 | - | 1-0-1 | 0 | 0 | 0 | - | - | - | - | - |
| ДДТТ 16 яшькә кадә,р | 4 | 5 | 4 | 8 | 0 | 4-1-4 | 7-0-9 | 4-0-4 | 8-1-9 | 6-0-6 | - | - | - | - | - |
| шул исәптән пассажирлар | 1 | 2 | 3 | 7 | 0 | 1-1-1 | 5-0-7 | 3-0-3 | 7-1-8 | 6-0-6 | - | - | - | - | - |
| Хайваннарны таптату | 4 | 18 | 13 | 23 | 6 | - | 1-0-1 | 0 | 1-0-2 | 0 | 4 | 12 | 13 | 22 | 0 |
| Башка вакыйгалар | 39 | 64 | 73 | 97 | 53 | 1-0-1 | 1-0-1 | 0 | 0 | 0 | 39 | 50 | 73 | 97 | 15 |

А(саны) – Б (үлүчеләр)- В(имгәнүчеләр)

# Һәлакәт төрләре

| Еллар буенча | Барлыгы | | | | | Имгәнгән балалар белән | | | | | Матди зыян белән | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| һәлакәтләр төрләре | 2018 | | | | | 2018 | 2019 | 2020 | | | 2018 | | | | |
| Бәрелешләр | 377 | | | | | 9-0-2 | 8-1-18 | 12-5-22 | | | 368 | | | | |
| Авулар | 23 | | | | | 11-5-11 | 6-2-5 | 2-0-2 | | | 12 | | | | |
| Техник чараларны бәрдерү | 189 | | | | | 0 | 0 | 1-1-2 | | | 189 | | | | |
| Юлдан кырыйга төшүләр | 13 | | | | | 5-1-7 | 3-1-3 | 5-1-8 | | | 8 | | | | |
| Киртәләргә бәрелү | 42 | | | | | 0 | 0 | 0 | | | 42 | | | | |
| Балаларны, шул исәптән җәяүлене таптату | 4 | | | | | 4-0-4 | 11-4-10 | 8-3-5 | | | 0 | | | | |
| | 0 | | | | | 1-0-1 | | | | | 0 | | | | |
| Велосипедны, шул исәптән балаларны таптату | 2 | | | | | 2-0-2 | 2-0-2 | 0 | | | 0 | | | | |
| | 0 | | | | | 0 | 0 | 0 | | | 0 | | | | |
| ДДТТ 16 яшькә кадәр, шул исәптән пассажирлар | 0 | | | | | 0 | 0 | 0 | | | 0 | | | | |
| | 0 | | | | | 0 | 0 | 0 | | | 0 | | | | |
| Хайваннарны таптату | 0 | | | | | 0 | 0 | 0 | | | 0 | | | | |
| Башка вакыйгалар | 32 | | | | | 0 | 0 | 0 | | | 32 | | | | |

А(саны) – Б (үлүчеләр)- В(имгәнүчеләр)

## Юл-транспорт һәлакәтләрен ясау сәбәпләре

| | | Барлыгы | | | | | Имгәнгән балалар белән | | | | | Матди зыян белән | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2012 | 2014 | 2015 | 2016 | 2017 | 2012 | 2014 | 2015 | 2016 | 2017 | 2012 | 2014 | 2015 | 2016 | 2017 |
| УНС | Дәүләт | 2 | 1 | 2 | 0 | 0 | 2-2-5 | 1-0-1 | 1-2 | - | - | - | - | - | - | 0 |
| | шәхси | 9 | 10 | 7 | 13 | 12 | 9-11 | 11-2-19 | 7-1-15 | 13-2-14 | 5-0-9 | - | - | - | - | 7 |
| Тизлек | | 103 | 102 | 124 | 161 | 48 | 19-2-26 | 24-2-30 | 13-1-5 | 9-3-19 | 16-0-25 | 84 | 82 | 111 | 152 | 10 |
| үзу | | 10 | 5 | 2 | 5 | 12 | 3-2-3 | 0 | 2-0-3 | 5-0-7 | 1-0-2 | 7 | 5 | 2 | - | 7 |
| каршы чыгу | | - | 28 | 27 | 37 | 20 | - | 3-1-2 | 3-0-4 | 4-1-6 | 1-1-6 | - | 25 | 24 | 33 | 6 |
| Маневр ясау | | 309 | 242 | 362 | 347 | 148 | 1-1-3 | 2-0-2 | 1-0-1 | 0 | 0 | 308 | 240 | 361 | 347 | 172 |
| шул исәптән артка чигенү | | 261 | 345 | 412 | 393 | 169 | - | 0 | 0 | 0 | 0 | 261 | 345 | 412 | 393 | 138 |
| юл киселешләренә керү | | 143 | 157 | 165 | 186 | 92 | 8-0-12 | 4-0-4 | 4-1-7 | 1-0-2 | 6-0-8 | 135 | 154 | 161 | 185 | 112 |
| ара, ераклык | | 233 | 278 | 395 | 287 | 169 | 5-1-16 | 1-0-1 | 1-0-1 | 1-0-2 | 2-0-2 | 288 | 277 | 394 | 286 | 49 |
| Җәяүлеләр гаебе белән | | 3 | 1 | 3 | 1 | 2 | 3-0-3 | 2-0-3 | 3-0-3 | 1-0-1 | 6-3-3 | - | - | - | - | 2 |
| Башка хокук бозулар | | 63 | 112 | 218 | 89 | 35 | 4-0-5 | 1-0-1 | 4-0-6 | 5-1-5 | 2-0-3 | 59 | 111 | 214 | 84 | 18 |
| 3 елга кадәр машина йөртүчеләр | | - | - | - | - | - | 12-3-21 | 12-0-15 | 5-0-10 | 3-1-5 | - | - | - | - | - | 0 |

А(саны) – Б (үлүчеләр)- В(имгәнүчеләр)

# Юл-транспорт һәлакәтләрен ясау сәбәпләре

| | | Барлыгы | | | | | имгәнүче балалар белән | | | | | матди зыян белән | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2018 | 2019/10 | 2020 | 2021 | 2022 | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 |
| УНС | Дәүләт | 1 | 0 | | | | 1-0-1 | 3-3-1 | 6-2-12 | | | 0 | 0 | | | |
| | Шәхси | 18 | 6 | | | | 6-2-4 | | | | | 12 | 4 | | | |
| Тизлек | | 17 | 8 | | | | 12-4-7 | | | | | 5 | 0 | | | |
| Узу | | 8 | 5 | | | | 0 | 0 | | | | 8 | 5 | | | |
| Каршы як полосага чыгу | | 10 | 8 | | | | 2-0-3 | 3-0-5 | 4-0-8 | | | 8 | 5 | | | |
| Маневр ясау | | 185 | 178 | | | | 0 | 0 | | | | 185 | 178 | | | |
| шул исәптән артка чигенү | | 176 | 148 | | | | 0 | 0 | | | | 176 | 147 | | | |
| Юл киселешләренә керү | | 115 | 93 | | | | 3-0-3 | 0 | | | | 113 | 92 | | | |
| Ара, ераклык | | 143 | 56 | | | | 3-0-4 | 0 | | | | 140 | 54 | | | |
| Велосипедчы гаебе белән | | 1 | 1 | | | | 1-0-1 | 0 | 0 | | | 0 | 0 | | | |
| Җәяүлеләр гаебе белән | | 2 | 2 | | | | 2-0-2 | 11-4-10 | 8-3-5 | | | 0 | 0 | | | |
| Башка хокук бозулар:<br>- ТС белән идарә итү хокукы булмаган затлар;<br>-йөк транспорты йөртүчеләренең юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуы;<br>- 16 яшькә кадәрге балалар катнашында | | 6 | 0 | | | | 1-0-1 | 1-0-1<br>3-1-3<br>5-0-6 | 1-0-1<br>1-1-0<br>4-0-5 | | | 5 | 4 | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 елга кадәр машина йөртүчеләр | 0 | 0 | | | | 0 | 3-0-5 | 2-0-4 | | | 0 | 0 | | | |

А(саны) – Б (үлүчеләр)- В(имгәнүчеләр)



**ЮТҺ булу урыны**

| Булу урыны | | Барлыгы | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2012 | 2013 | 2014 | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 | 2019 |
| "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге | Барлыгы | 465 | 492 | 536 | 634 | 683 | 296 | 374 | 325 |
| | имгәнгән балалар белән | 13-0-19 | 11-1-13 | 10-10 | 4-0-4 | 4-1-4 | 2-0-3 | 7-0-7 | 3-1-2 |
| | матди зыян белән | 452 | 481 | 526 | 630 | 679 | 294 | 367 | 324 |
| Казан-Малмыж а/ю | Барлыгы | 166 | 242 | 251 | 184 | 332 | 86 | 129 | 73 |
| | имгәнгән балалар белән | 18-5-34 | 25-8-44 | 16-3-21 | 6-1-5 | 14-3-24 | 6-0-8 | 11-2-18 | 11-2-20 |
| | матди зыян белән | 148 | 217 | 236 | 178 | 318 | 80 | 118 | 65 |
| Арча - Мари Иле чиге а/ю | Барлыгы | 54 | 60 | 97 | 105 | 142 | 33 | 26 | 12 |
| | имгәнгән балалар белән | 11-2-19 | 10-11 | 6-1-9 | 4-1-4 | 4-0-4 | 7-1-7 | 2-1-1 | 5-2-3 |
| | матди зыян белән | 43 | 50 | 91 | 101 | 138 | 26 | 24 | 10 |
| Арча - Олы Әтнә а/ю | Барлыгы | 16 | 29 | 35 | 27 | 55 | 18 | 20 | 13 |
| | имгәнгән балалар белән | 0-0-0 | 1-3-0 | 2-0-3 | 2-03 | 0 | 3-0-4 | 0 | 0 |
| | матди зыян белән | 16 | 28 | 33 | 26 | 55 | 15 | 20 | 13 |
| Арча - Сеҗе а/ю | Барлыгы | 21 | 12 | 37 | 40 | 66 | 18 | 23 | 14 |
| | имгәнгән балалар белән | 2-0-2 | 3-0-3 | 8-0-14 | 1-0-1 | 4-1-6 | 0 | 3-2-1 | 2-1-1 |
| | матди зыян белән | 19 | 9 | 29 | 39 | 62 | 18 | 20 | 12 |
| Арча - Теләче а/ю | Барлыгы | 18 | 45 | 50 | 65 | 90 | 17 | 24 | 19 |
| | имгәнгән балалар белән | 2-0-2 | 2-0-4 | 4-1-6 | 3-0-3 | 2-0-2 | 0 | 2-0-3 | 3-0-4 |
| | матди зыян белән | 16 | 43 | 46 | 62 | 88 | 17 | 22 | 17 |
| Башка юллар | Барлыгы | 30 | 97 | 33 | 55 | 98 | 28 | 35 | |
| | имгәнгән балалар белән | 6-2-6 | 5-1-5 | 6-7 | 6-1-9 | 9-2-13 | 5-1-9 | 5-1-5 | 3-2-2 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | матди зыян белән | 34 | 92 | 27 | 51 | 89 | 29 | 30 | 18 |
| Башка торак пунктлар | Барлыгы | 92 | 119 | 74 | 90 | 126 | 29 | 51 | 30 |
| | имгәнгән балалар белән | 6-0-6 | 4-1-3 | 0 | 1-0-1 | 2-0-3 | 2-0-3 | 1-0-1 | 3-0-6 |
| | матди зыян белән | 86 | 115 | 74 | 89 | 124 | 26 | 50 | 28 |

А(саны) – Б (үлүчеләр)- В(имгәнүчеләр)

| Булу урыны | | Барлыгы | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 | 2021 | 2022 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | 2026 |
| "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге | Барлыгы | | | | | | | | |
| | имгәнгән балалар белән | 1-0-1 | | | | | | | |
| | матди зыян белән | | | | | | | | |
| Казан -Малмыж а/ю | Барлыгы | | | | | | | | |
| | имгәнгән балалар белән | 9-4-13 | | | | | | | |
| | матди зыян белән | | | | | | | | |
| Арча- Мари Иле чиге а/ю | Барлыгы | | | | | | | | |
| | имгәнгән балалар белән | 7-5-8 | | | | | | | |
| | матди зыян белән | | | | | | | | |
| Арча-Олы Әтнә а/ю | Барлыгы | | | | | | | | |
| | имгәнгән балалар белән | 2-0-6 | | | | | | | |
| | матди зыян белән | | | | | | | | |
| Арча - Сеҗе а/ю | Барлыгы | | | | | | | | |
| | имгәнгән балалар белән | 1-0-2 | | | | | | | |
| | матди зыян белән | | | | | | | | |
| Арча - Теләче а/ю | Барлыгы | | | | | | | | |
| | имгәнгән балалар белән | 1-0-1 | | | | | | | |
| | матди зыян белән | | | | | | | | |
| Башка юллар | Барлыгы | | | | | | | | |
| | имгәнгән балалар белән | 7-2-8 | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | матди зыян белән | | | | | | | | |
| Башка торак пунктлар | Барлыгы | | | | | | | | |
| | имгәнгән балалар белән | | | | | | | | |
| | матди зыян белән | | | | | | | | |

**2019 елда машина йөртүчеләрнең яшәү урыны буенча юл-транспорт һәлакәтендә зыян күрүчеләргә анализ**

| | Арча районы | ТР халкы | РФ төбәкләрендә яшәүчеләр |
|---|---|---|---|
| | Барлыгы | Барлыгы | Барлыгы |
| Арча шәһәре | 283 (1-0-1) | 26 | 5 |
| Казан-Малмыж а/ю | 47 (4-1-4) | 12 (4-1-13) | 6 |
| Арча-Мари Иле а/ю | 9 (1-0-1) | 2 | 1-1-0 |
| Арча-Олы Әтнә а/ю | 11 | 2 | 0 |
| Арча-Сеҗе а/ю | 9 (2-1-1) | 3 | 0 |
| Арча – Теләче а/ю | 15 (2-0-2) | 2 | 0 |
| Башка юллар | 17 (4-2-4) | 1 | 0 |
| Башка торак пунктлар | 25 (2-0-4) | 3 | 0 |
| Барлыгы | 416 (16-4-17) | 50 (4-1-13) | 21 (1-1-0) |

**ЮТҺ профилактикалау**

| № | Исеме | 2012 | 2013 | 2014 | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | УНС | 194 | 175 | 192 | 93 | 132 | 168 | 158 | 111 | 158 |
| 2 | Узып китү (12.15 сәг. 4) | 19 | 271 | 283 | 195 | 211 | 211 | 200 | 193 | 149 |
| 3 | Таныклыксыз машина йөртү(12.7 1 о.) | 40 | 29 | 37 | 21 | 40 | 40 | 17 | 23 | 13 |
| 4 | Мәхрүм ителгәннәр (12.7 2 ө.) | 29 | 35 | 25 | 13 | 26 | 23 | 22 | 6 | 4 |
| 5 | Балаларны СДУУ сыз йөртү | 388 | 299 | 135 | 175 | 223 | 195 | 143 | 106 | 120 |
| 6 | Каеш (12.6) | 1930 | 1928 | 1638 | 1318 | 2147 | 1539 | 1756 | 1315 | 1511 |
| 7 | Җәяүлеләргә юл бирү (12.18) | 161 | 165 | 202 | 222 | 237 | 177 | 191 | 358 | 358 |
| Барлыгы хокук бозулар | | 2761 | 2902 | 2512 | 2037 | 3016 | 2353 | 2487 | 797 | 2313 |

Юл-транспорт һәлакәтләре икътисадка шактый зыян китерә:

- амбулатор һәм стационар дәвалауга, зыян күрүчеләрне һәм һәлак булганнарны транспортлауга чыгымнар;

- реабилитациягә чыгымнар;

- кешеләрнең үлеме яки даими эшкә сәләтсезлеге аркасында алынмаган продукциядән чыгымнар;

- мөлкәткә зыян китерү, юл буе коммуникацияләрен торгызу белән бәйле чыгымнар;

- юл-транспорт һәлакәтләре сәбәпләрен тикшерү, иминият суммалары түләүләрен оештыру, суд чыгымнары;

- вакыт югалту белән бәйле чыгымнар.

Туганнарына, якыннарына, юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булган һәм имгәнгән кешеләрнең хезмәттәшләренә китерелгән әхлакый зыян бәяләп бетергесез.

Муниципаль районның автомобиль юлларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтү һәм алардан килгән зыяннарның авырлыгын киметү бүгенге көндә башкарма хакимиятнең мөһим бурычларыннан берсе булып тора.

2020 елның 12 ае нәтиҗәләре буенча авария күрсәткече 28-11-39 тәшкил итә.

«2013-2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген үстерү» федераль максатчан программасы күрсәткечләрен һәм фаразланган максатчан индикаторларны үтәү: 9 һәлак булучы фаразлаган-үтәлмәгән.

2020 елның 12 ае нәтиҗәләре буенча юл-транспорт һәлакәте нәтиҗәсендә үлүчеләр санын киметүнең максатчан күрсәткече, "БКАД" илкүләм проекты нигезендә арттырылган (исәп-хисап максатчан күрсәткече 8 булса, юл-транспорт һәлакәтендә 11 кеше һәлак булган).

2020 елның 12 аенда зыян күрүчеләр белән 28 юл-транспорт һәлакәте булган, алар вакытында 11 кеше һәлак булган һәм 39 кеше имгәнгән. 2019 елгы АПГ белән чагыштырганда, һәлак булучылар саны 3 кешегә арткан.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, кешеләрнең төп өлеше төбәк әһәмиятендәге гомуми файдаланудагы юлларда һәлак булган.

Арча муниципаль районында аварияләр булу сәбәпләрен билгеләүче төп факторлар:

- транспорт чаралары белән идарә иткәндә, юл хәрәкәтендә катнашучылар тарафыннан юл хәрәкәте кагыйдәләренә битарафлык, начар дисциплина, машина йөртүчеләрнең игътибарсызлыгы;

- юл хуҗалыкларының техник дәрәҗәсенең, юл хәрәкәтен оештыру чараларының заманча таләпләргә туры килмәве;

Районда үлүчеләр белән булган юл-транспорт һәлакәтләренең төп торләре бәрелешләр, аву һәм җәяүлеләрне бәрдерү.

Районда һәлак булучылар белән булган юл-транспорт һәлакәтләренең төп сәбәпләре: тизлекне арттыру, каршы як хәрәкәт полосасына чыгу, тыелган участокларда узу, юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозып юл чатларында йөрү, исерек хәлдә транспорт чаралары белән идарә итү.

Программа-максатчан метод булмау шартларында һәлакәтлекнең котелгән күрсәткече 1 нче кушымтада китерелгән.

## II. ПРОГРАММАНЫҢ ТӨП МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

Программаның максаты-юл-транспорт һәлакәтләреннән (шул исәптән балалар) үлүчеләр һәм зыян күрүчеләр булган юл-транспорт һәлакәтләре санын киметү, гражданнарның тормышын, сәламәтлеген һәм аларның мөлкәтен саклауны тәэмин итү, район юллары буенча хәрәкәтнең имин шартларына аларның законлы хокукларын гарантияләүне арттыру.

Программаның бурычлары:

- кешеләрнең һәлак булу ихтималы аеруча зур булган юл-транспорт һәлакәтләрен булдырмау;

- юл-транспорт һәлакәтләрендә имгәнүләрне киметү;

- юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтүнең заманча системасын үстерү;

- юл хәрәкәте иминлеген үстерү буенча эшчәнлек белән идарә итү системасын камилләштерү;

- юл хәрәкәтендә катнашучыларның хокукый аңын һәм җаваплылыгын үстерү;

- җирле әһәмияттәге юлларда куркыныч урыннарны бетерү;

- урамнарда һәм юлларда юл хәрәкәте кагыйдәләрен өйрәтү системасын камилләштерү.

Аварияле лек күрсәткечләренә ирешүнең көтелгән үсеше Программага 2 нче кушымтада китерелгән.

## III. ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ

2021 елга Программа чаралары исемлеге 3 нче кушымтада чагылдырылган.

Программа чаралары транспорт чаралары һәм җәяүлеләрнең хәрәкәт шартларын яхшыртуны, транспорт агымнарын җайга салуны, хәрәкәтне оештыру буенча эшләнгән проектларны һәм юл хәрәкәтен оештыруның комплекслы схемасын куллануны, җәяүлеләр хәрәкәтен оештыруны камилләштерүне, юл-транспорт һәлакәтләре килеп чыгуга юл шартларының йогынтысын киметүне, юл-транспорт һәлакәтләре концентрацияләнгән урыннарда инженерлык чаралары уздыруны күздә тота.

## IV. ПРОГРАММАНЫ РЕСУРСЛАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ

2021 елгы программа чараларын финанслау 3 007 858,74 сум күләмендә муниципаль берәмлек бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашыру планлаштырыла.

## V. ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ МЕХАНИЗМЫ

### Программаны тормышка ашыру белән идарә итүнең оештыру-хокукый аспектлары

Программаны гамәлгә ашыру белән идарә итүне Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты башкара.

Программаны тормышка ашыруда Арча муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча ЮХИДИ бүлекчәсе, Арча районындагы «Юл хәрәкәте имилеге» ДБУ бүлекчәсе, массакүләм мәгълүмат чаралары катнаша.

Программада катнашучыларның үзара хезмәттәшлеген Арча муниципаль районы Башкарма комитетының юл хәрәкәте иминлеге буенча комиссия гамәлгә ашыра.

Арча муниципаль районы Башкарма комитетының юл хәрәкәте иминлеге буенча комиссия түбәндәге төп функцияләрне башкара:

- киләсе финанс елына Программа чараларының еллык планы проектын әзерләү һәм Программаны дәүләт заказчылары белән килештерүгә кагылышлы мәсьәләләр буенча эшчәнлекне координацияләү;

- Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм төрле оештыру-хокукый формадагы оешмалар белән үзара яраштырылган хезмәттәшлек буенча чаралар комплексын үтәү;

- Программа чараларын тормышка ашыру турында статистик һәм аналитик мәгълүматны җыю һәм системалаштыру;

- Программа чараларын тормышка ашыру нәтиҗәләренә мониторинг, әлеге чараларны тормышка ашыру турында аналитик мәгълүмат формалаштыру һәм Программаны тормышка ашыру турында хисап әзерләү;

-Программа чараларының нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен, нәтиҗәлелеген һәм аларның индикаторларына һәм күрсәткечләренә туры килүен бәйсез бәяләүне оештыру;

- Программаны гамәлгә ашыру барышы һәм нәтиҗәләре турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру.

**Программаны тормышка ашыру белән идарә итүнең финанс аспектлары**

Программаны тормышка ашыруга кирәкле финанс чыгымнары 3 нче кушымтада (финанслау объектларының адреслы исемлеге) чагылдырылган.

Программаның гамәлдә булуы аны гамәлгә ашыру тәмамлау, муниципаль район бюджетында өстәмә керемнәр булмаган очракта, вакытыннан алда туктату - Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары нигезендә аны гамәлгә ашыру нәтиҗәсез дип танылган очракта башкарыла.

Инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Р.Р. Фазыйлов

"2021 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген үстерү" муниципаль программасына 1 нче кушымта

## Программа-максатчан метод булмаган шартларда көтелгән авариялелек күрсәткечләре

| Авариялелек күрсәткече | 2012 ел | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ЮТҺ нәтиҗәсендә һәлак булган затлар саны | 9 | 19 | 16 | 16 | 17 | 17 | 17 | 18 | 18 | 18 |

"2021 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген үстерү" муниципаль программасына 2 нче кушымта

## 2021 елда Татарстан Республикасы территориясендә юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә үлүчеләр санын киметүнең максатчан юнәлешләре («Имин һәм сыйфатлы автомобиль юллары» илкүләм проекты)

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ТАТАРСТАН | 21 | 45 | 58 | 73 | 97 | 129 | 179 | 210 | 248 | 285 | 312 | 335 |
| Арча | 0 | 1 | 2 | 2 | 3 | 3 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 7 |

**"2021 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген үстерү» муниципаль программасы чаралары**

| № | Юл хәрәкәте иминлеген үстерү буенча муниципаль программа чараларының исеме | Адресы | Эшләр күләме | Үлчәү берәмлеге | Үлчәү берәмлеге өчен смета бәясе, сум | Гомуми смета бәясе, сум | Финанслау чыганагы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Яңа юл билгеләре урнаштыру | "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге ДУС | 50,00 | данә | 3459,20 | 172 960,00 | Җирле бюджет | ТР Финанс министрлыгының Казначылык Департаменты белән килештерелгән төзекләндерү чыгымнары сметасы |
| 2 | Юл билгеләре калканнарын алыштыру | "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге ДУС | *60,00* | *данә* | *2194,00* | *131 640,00* | Җирле бюджет | ТР Финанс министрлыгының Казначылык Департаменты белән килештерелгән төзекләндерү чыгымнары сметасы |
| 3 | Горизонталь күчәрле юл тамгасы төшерү | "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге ДУС | 10033,00 | м | - | 790 273,52 | Җирле бюджет | Юл хәрәкәтен оештыру проекты нигезендә. |
| 4 | Җәяүлеләр өчен көйләнми торган кичүләрдә «ЗЕБРА» (1.14.1) горизонталь юл билгеләрен сары-ак төстәге урнаштыру | "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге ДУС | 2451,20 | кв.м. | - | | | ТР Финанс министрлыгының Казначылык Департаменты белән килештерелгән төзекләндерү чыгымнары сметасы |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5 | "Арча шәһәре" муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге юл-урам челтәре (авыл жирлекләренең юл-урам челтәре - вак таш яки асфальтобетон өслеге белән) чокырларын ремонтлау. | "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге ДУС | 1743,00 | кв.м. | 999,36 | 1 741 885,22 | Җирле бюджет | ТР Финанс министрлыгының Казначылык Департаменты белән килештерелгән төзекләндерү чыгымнары сметасы |
| 6 | Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы темасына социаль реклама урнаштыру | Муниципаль милектәге биналар һәм муниципаль торак фонды биналары | 4,00 | данә | 25000,00 | 100 000,00 | Җирле бюджет | Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе карарлары. |
| 7 | Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләрне (беренче сыйныф укучыларын) 2021 елның 1 сентябренә кадәр яктылык кайтаручы элементлар белән тәэмин итү. | Арча муниципаль районы укучылары | *711,00* | *компл.* | *100,00* | *71 100,00* | Җирле бюджет | Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе карарлары. |
| | Барлыгы, сум | | | | | **3 007 858,74** | | |

Инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Р.Р.Фазыйлов

«2021 елга Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районында
юл хәрәкәте иминлеген үстерү"
муниципаль программасына
4 нче кушымта

**"Имин һәм сыйфатлы автомобиль юллары" илкүләм проектының максатчан күрсәткечләре (Россия Федерациясе Президентының "2024 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары һәм стратегик бурычлары турында" 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указын, "Имин һәм сыйфатлы автомобиль юллары" илкүләм проект паспортын (Россия Федерациясе Президенты каршындагы стратегик үсеш һәм милли проектлар советы президиумы - 2018 елның 24 декабрендәге 15 номерлы беркетмә) үтәү йөзеннән Россия Федерациясе Транспорт министрлыгы тарафыннан эшләнде)**

| № | | Үлчәү берәмлеге | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Юл-транспорт һәлакәте нәтиҗәсендә үлүчеләр саны киму | кеше, фараз | 8 | 8 | 8 | 9 - ФЦП<br>8 - БКАД | 7 | 2 | 2 | 1 | | |
| 2 | Юл-транспорт һәлакәте нәтиҗәсендә үлүчеләр саны киму | кеше, факт | 4 үтәлгән | 6 үтәлгән | 8 үтәлгән | 11 Үтәлмәгән | | | | | | |